БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
10 ноябрь 2025 ел

**КАРАР**
№ 19

**Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законына (2025 елның 20 мартындагы редакция) туры китереп һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Балтач район Советының 2014 елның 22 октябрендәге 250 номерлы карары белән расланган (2015 елның 17 апрелендәге 273номерлы, 2015 елның 16 июлендәге 287 номерлы, 2023 елның 23 мартындагы 175 номерлы үзгәрешләр белән) Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 16 пунктның 2 абзацында «яисә алар тарафыннан тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләрен «үз чыгымнары турында белешмәләр, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү (федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш) йә күрәләтә ялган мәгълүмат тапшыру» сүзләренә, «яисә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшырмау, белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләрен «яисә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшырмау, белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру (федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш), йә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган

балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н. Сабирҗанов